**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

14 нче ноябрь 2016 ел №82

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегендә 2015 елның 17 мартындагы 232 номерлы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы карары белән расланган Муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 февралендәге №25-ФЗ Федераль закон нигезендә, 2016 елның 23 маенда кабул ителгән 143-ФЗ номерлы «Гражданнарның аерым категорияләренә пенсия яшен арттыру өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы 2015 елның 17 мартындагы 232 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында»гы нигезләмәгә (алга таба – нигезләмә), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

22 бүлекнең 22.2 пунктының беренче абзацында «15 ел» сүзләрен «тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен аның озынлыгы гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат Олы Ачасыр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Олы Ачасыр авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**